Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Верхнешипкинского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Шепкә авыл
җирлегенең
башкарма комитеты

ул.Молодежная, д.1, с.Верхние
Шипки, Заинский район, 423518

Яшьләр урамы, 1 нче йорт,
Югары Шепкә авылы, Зәй
районы, 423518

Телефон, факс 6-92-77. Электронный адрес:Vship.Zai@tatar.ru, сайт:
http://shipki.jimdo.com

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 30 января 2024 года** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2024 елның 23 январендагы 46 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2024 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370,20 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2023 елның 03 февралендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Л.М. Камалиева**

Зәй муниципаль районы
Югары Шепкә авыл җирлеге
башкарма комитетының
«30» январендә 2024ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2024 елның 01 февраленнән
Югары Шепкә авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3183,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1360,74 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3825,86 |
| Барысы | 8370,20 |

Зәй муниципаль районы
Югары Шепкә авыл җирлеге
башкарма комитетының
«30» январендә 2024ел
2номерлы карарына
2 нче кушымта

2024 елның 01 февраленнән
Югары Шепкә авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 872,95 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2375,87 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1328,21 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3793,17 |
| Барысы | 8370,20 |